**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 март № 157

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын тормышка ашыру турында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карары белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге юридик хокуклы гражданнар өчен тәрбиягә алган гаилә төзү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын тормышка ашыру турында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карары белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге юридик хокуклы гражданнар өчен тәрбиягә алган гаилә төзү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 нче пунктта «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәгенә яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 нче пунктта «дүртьяклы» сүзен «өчьяклы» сүзенә алмаштырырга, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Матди түләүләр үзәге),» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 нче пунктта:

беренче абзацта «дүрт» сүзен «өч» сүзенә алмаштырырга, «, Матди түләүләр үзәгенә» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «, Матди түләүләр үзәге өчен – өч эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.7 нче пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) ярдәмчегә Россия Федерациясе Президентының «Хезмәткә яраксыз гражданнарны карауны гамәлгә ашыручы затларга компенсация түләүләре турында»

2006 ел, 26 декабрь, 1455 нче Указы нигезендә I төркем инвалидын (балачактан I төркем инвалидларыннан тыш) , шулай ук дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими башка кеше каравына мохтаҗ яисә 80 яшенә җиткән карт кешене карауны гамәлгә ашыручы эшләми торган хезмәткә яраклы зат буларак айлык компенсация түләве билгеләнгән.»;

4.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Комплекслы үзәк:

һәр ярдәмче тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган өлкән яшьтәге гражданнар саны, өлкән яшьтәге гражданның тәрбиягә алган гаиләдә яшәгән көннәре саны, күчерелергә тиешле сумма турында мәгълүматларны үз эченә алган ярдәмчеләр реестрын (алга таба – Реестр) Министрлык раслаган форма буенча төзи;

реестрлар нигезендә, Россия Федерациясе Салым кодексының 34 бүлегенә ярашлы рәвештә иминият кертемнәре исәпләү һәм күчерү өчен кирәкле акча күләмен исәпкә алып, айлык акчалата түләүләр бирү өчен финанс чыгымнарына җыелма заявка (алга таба – җыелма заявка) формалаштыра;

айлык акчалата түләү бирелә торган айдан (алга таба – хисап ае) соң килә торган айның 3есенә кадәр Министрлыкка җыелма заявканы җибәрә.»;

4.3 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

4.4 нче пунктта «10ысына кадәр» сүзләрен «5есенә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хисап аеннан соң килә торган айның 10ысына кадәр айлык акчалата түләүләр бирү өчен кирәкле финанслауның чик күләмен (алга таба – финанслауның чик күләме) Министрлыкка җиткерә.»;

4.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Министрлык финанслауның чик күләме җиткерелгән көннән соң ике эш көне эчендә Комплекслы үзәк белән Башка максатларга субсидия бирүгә килешү төзи һәм субсидияне Комплекслы үзәкнең шәхси счетына күчерә.»;

4.7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Комплекслы үзәк:

шартнамә һәм реестр нигезендә ай саен хисап аеннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, ярдәмче сайлавы буенча ярдәмченең үзе сайлаган банкта яки бүтән кредит оешмасында булган яки ачылган банк счетына яисә сорап алганга кадәр кертемгә айлык акчалата түләүне күчерә;

законнарда билгеләнгән вакытта иминият кертемнәрен исәпли һәм күчерә.»;

4.10 нчы пунктта «Матди түләүләр үзәге» сүзләрен «Комплекслы үзәк» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\157.doc